СОВЕТ
НОВОИШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ИШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Яңа Ишле авылы

13 нче ноябрь 2020 ел № 3/3

"Җир салымы турында" гы
карарга үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы авыл җирлеге Советы, Россия Федерациясе Салым кодексына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Уставына туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Советының «җир салымы турында» 2019 елның 5 ноябрендәге 51/4 номерлы карарының 4 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«узган чордан соң килүче икенче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга;

«елның 5 февраленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «Россия Федерациясе Салым кодексының 397 статьясында билгеләнгән срокларда»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән (халыкка игълан ителгән көннән) бер айдан да иртәрәк түгел.

3. Әлеге карарны Яңа Ишле авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Яңа Ишле авыл җирлеге сайтында урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

Яңа Ишле авыл җирлеге башлыгы: Р.У.Мухаметзянов